КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 октябрь г.Казань № 924

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең Кара диңгез яр буенда шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлешле смена буенча ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына кararга теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 09 сентябрь, 754 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең Кара диңгез яр буенда шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлешле смена буенча ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт – Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе өчен Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын билгеләү турында» 2023 ел, 26 октябрь, 1354 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 25 октябрь, 924 нче
карары белән расланды

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 754 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең Кара диңгез яр буенда шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлешле смена буенча ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентлары

| Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе* | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең Кара диңгез яр буенда шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлешле смена буенча ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентлары | 1,21906 | 1,21544 | 1,20906 |

*Төзәтү коэффициентлары 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт – Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең Кара диңгез яр буенда шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлешле смена буенча ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен билгеләгәндә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан кулланыла.